**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән министры**

**_________________И.Г. Һадиуллин**
**«___» __________ 2023 ел**

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар укучылары өчен 2024 елда туган (татар) телдән бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2024 году единого республиканского экзамена по родному (татарскому) языку для обучающихся-татар школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтиханны башкаруга 210 минут вакыт бирелә. Ул вакыт эчендә укучылар 3 өлештән торган эшне башкарып чыгарга тиеш.

Беренче өлеш 30 биремне (1-30) үз эченә ала. Һәр биремгә тәкъдим ителгән 4 вариант җавапның берсен, ягъни дөресен генә сайлап алырга кирәк.

Икенче өлеш кыска җавапны таләп иткән 8 биремнән (31-38) гыйбарәт. Бу биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк.

Өченче өлеш бер биремнән (39) гыйбарәт һәм текстка бәйле зур булмаган язма эшне (иншаны) тәшкил итә.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәргә киңәш итәбез. Аларны үтәү барышында кыенлык тудырганы очраса, әлеге биремне калдырып торып, алдагысына күчегез. Вакыт калган очракта, сез бу биремнәргә кабат әйләнеп кайта аласыз.

Дөрес җавап, катлаулылыгыннан чыгып, 1 яки югарырак балл белән бәяләнә. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

**Уңышлар телибез!**

## 1 нче өлеш

***1-30 нчы биремнәрнең җавабы сан белән күрсәтелә. Җавапларны 1 нче номерлы җавап бланкына, кирәкле бирем номерыннан уң якка, беренче шакмактан башлап язып куярга кирәк.***

**1.** Сүзнең әдәби әйтелеш нормасын билгеләгез.
1) [йөзэнэң]
2) [йөзөнэң]
3) [йөзөнөң]
4) [йөзэнэн]

**2.** Алынма сүзне билгеләгез.
1) эшкуар
2) эшләпә
3) эшләнмә
4) эшчәнлек

**3.** Антоним сүзләрне билгеләгез.
1) тәүге – соңгы
2) тәүге – әүвәлге
3) тәүге – беренче
4) тәүге – башлангыч

**4.** Тамыр сүзне билгеләгез.
1) сугыш
2) сукмак
3) суккыч
4) сукыр

**5.** *Ученый* сүзенең татарчага дөрес тәрҗемәсен билгеләгез.
1) гамәл
2) галим
3) гайрәт
4) галәм

***Текстны укыгыз һәм 6 – 11 нче биремнәрне үтәгез.***

1) Һәркемгә мәгълүм хакыйкать шул: урманнан башка тормыш юк. 2) Тик барыбер вәхшиләрчә урманнарны кыру дәвам итә. 3) Кем дөреслекне аңларга теләми <...> шул табигатькә кул сала. 4) Урманчы галимнәр әйткәнчә, Җир шары пеләшләнә бара. 5) Чәчүлек мәйданнарын, көтүлекләрне киңәйтү максатыннан чыгып, ягулык өчен һәм агач эшкәртү промышленносте чималы буларак киселгән урманнар дөньяда 4,2 миллиард гектарга җитә. 6) Моның нәтиҗәсендә ландшафтның экологик бөтенлеге бозыла башлады: зур мәйданнарда туфрак бозыла, су басу яки корылык көчәя, җирләрнең продуктлылыгы кими.

7) Галимнәр күмер, нефть, табигый газ яндырудан җирнең уртача температурасы 3-5 градуска күтәрелергә тиеш дип фаразлыйлар. 8) Бу хәл, поляр өлкәләрдәге бозларны эретеп, дөнья океаны өслеген 5-7 метрга күтәрү һәм киң мәйданнардагы түбәнлекләрне, андагы урманнарны су астында калдыру куркынычын тудыра.

*(Вакытлы матбугаттан)*

**6.** 5 нче җөмләдә кулланылган *промышленносте* сүзенең татарча вариантын билгеләгез.
1) сәгадәте
2) сәгате
3) сәнәгате
4) сәнгате

**7.** 4 нче җөмләдә кулланылган *урманчы* сүзенең русчага тәрҗемәсен билгеләгез.
1) лесистый
2) лесничество
3) лесной
4) лесник

**8.** 1 нче җөмләдә кулланылган сыйфатны билгеләгез.
1) һәркемгә
2) мәгълүм
3) хакыйкать
4) тормыш

**9.** Әлеге өзекнең кайсы стильгә каравын билгеләгез.
1) матур әдәбият стиленә
2) рәсми эш кәгазьләре стиленә
3) публицистик стильгә
4) фәнни стильгә

**10.** 6 нчы җөмләнең төрен билгеләгез.
1) гади җөмлә
2) күп иярченле кушма җөмлә
3) тезмә кушма җөмлә
4) катнаш кушма җөмлә

**11.** 3 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез.
1) ике нокта
2) сызык
3) нокталы өтер
4) өтер

**12.** Күп нокталар урынына куелырга тиешле тыныш билгеләрен билгеләгез.

*Язма <...> басма сүз <...> кешелек дөньясы уйлап чыгарган иң бөек могҗизаларның берсе. (М.Әгъләмов)*

1) өтер, сызык
2) өтер, өтер
3) сызык, өтер
4) өтер, ике нокта

**13.** Күп нокталар урынына *ң* хәрефе языла торган очракны билгеләгез.
1) я...ган
2) и…күлек
3) яла…гач
4) сә…гать

**14.** Күп нокталар урынына куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез.

*Ат <...> табигать тарафыннан яратылган мәһабәт һәм көчле хайван.*

1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) тыныш билгесе куелмый.

**15.** Аерып бирелгән сүзнең кайсы җөмлә кисәге булуын билгеләгез.

***Һәр*** *халыкта канатлы сүзләр күп.*

1) аергыч
2) тәмамлык
3) хәл
4) аныклагыч

**16.** Түбәндә бирелгән сүзләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт урнашкан очракны билгеләгез.
1) якты бүлмә
2) бүлмә якты
3) якты бүлмәдә
4) якты бүлмә өчен

**17.** Күп нокталар урынына *ө* хәрефе язылырга тиешле сүзне билгеләгез.
1) м...лкәт
2) м...рас
3) м...чкә
4) м...лләт

**18.** Дөрес язылышны билгеләгез.
1) җәеы
2) җәйэ
3) җәйе
4) җәе

**19.** Сүзләр кушылып язылган очракны билгеләгез.
1) оек(баш)
2) олысы(кечесе)
3) озын(озак)
4) оча(куна)

**20.** Тартым кушымча дөрес ялганмаган сүзне билгеләгез.
1) кристаллы
2) үлчәве
3) линиясе
4) тарагы

**21.** Юлдан-юлга күчерүнең дөрес очрагын билгеләгез.
1) макт-ады-лар
2) мак-та-ды-лар
3) мактад-ылар
4) ма-кта-ды-лар

**22.** Артык сүзне билгеләгез.
1) тыйнак
2) басынкы
3) тотнаклы
4) тынгысыз

**23.** Сүзнең дөрес язылышын билгеләгез.
1) табигать
2) тәбигәть
3) тәбигать
4) табигәт

**24.** Күп нокталар урынына куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез.

*Күрәсең <...> бүген ясамаулар да мөмкин. (Э. Касыймов)*

1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) тыныш билгесе куелмый

**25.** *Жеребенок* сүзенең татар теленә дөрес тәрҗемәсен билгеләгез.
1) койрык
2) колга
3) колын
4) койма

**26.** Дөрес тәрҗемә ителмәгән сүзне билгеләгез.
1) мөмкин – можно
2) мөлкәт – имущество
3) мөнәсәбәт – отношение
4) мөгез – труба

**27.** Сүзнең дөрес язылышын билгеләгез.
1) хакыйкәть
2) хакыйкат
3) хакыйкать
4) хакикать

***Текстны укыгыз һәм 28-30, 31 – 38, 39 нчы биремнәрне эшләгез.***

1) Барысы да шул китаплар укудан башланды инде. 2) Чөнки бөтенесендә батырлар турында язылган. 3) Берсе – суда батучыны, икенчесе баланы ***янгыннан*** коткарган. 4) Әле тагын күпме шундый китаплар бардыр.

5) Батырлык!

6) Их, берәр батырлык эшләсәң икән ул. 7) Эшләр идең дә, кешеләр сиңа:

– Исәнме, Хәлим батыр! – диярләр иде. 8) Нинди рәхәт булыр иде. 9) Тик әле болар хыял гына. 10) Ләкин мин дә берәр батырлык эшләячәкмен. 11) Ул вакытта:

– Укымыйсың, тәртип бозасың, – дип бәйләнеп йөрүче сыйныфташым Зәнфирәнең дә авызы капланыр. 12) Ә мин аңа эндәшмәм дә. 13) Менә күрерсез!

14) Шундый уйлар белән кыш үтте, яз җитте. 15) Ләкин батырлык эшләп булмый гына бит. 16) Батырлар түземле <…> чыдам булалар икән. 17) Укыган китапларымдагы шул сүзләр искә төшә дә күңелгә рәхәт булып китә. 18) Димәк <…> күтәргә!

19) Бүген мәктәптән кайткач, кулыма озын таяк алдым да елга буена төшеп киттем. 20) Язгы ташу азрак тынды тынуын, шулай да күңелдә бер уй кайный әле: суга дип төшкән берәр апа бата башламасмы икән? 21) Әгәр бата башласа, мин аңа ярдәмгә ташланачакмын, үзен судан тартып чыгарырмын. 22) Шулай итеп, батыр булачакмын.

23) Тик елга буйлап ике-өч мәртәбә урап килсәм дә, андый нәрсә күзгә чалынмады. 24) Өметемне өзеп, кайтырга торганда, су буена төшеп килүче бала-чага тавышы ишетелде. 25) Мин тизрәк шунда йөгердем. 26) Анда Зәнфирәнең сеңлесе Фәния, тагын бер-ике кызчык иде. 27) Булды бу болай булгач, дип уйлап алдым мин.

28) – Әй, сез, – дим, – боз өстендә йөзәсегез киләме?

29) – Килә, Хәлим абый, бик тә килә! –диләр. 30) Шатланышып, яныма йөгереп килделәр.

31) – Утырыгыз менә шушысына! – дидем мин, яр кырыенда яткан бозга күрсәтеп. 32) Үзем алдагы басмага карап-карап алам. 33) Янәсе, кызларны агызып җибәрәм дә, йөгереп барып, басмадан берәм-берәм эләктереп алам үзләрен. 34) Кызлар боз өстенә менеп басуга, яр башыннан торып, таяк белән аны кузгатырга тотындым. 35) Боз кисәге кузгалмый да, кузгалмый гына бит. 36) Менә бер заманны... 37) Бер заманны, таягым сынып китеп, үзем яр астына мәтәлдем. 38) Кызларга нәрсә, көлешә-көлешә, ярдәмгә ашыктылар. 39) Тырыша торгач, судан да тартып чыгардылар. 40) Мин, итек эченә тулган бозлы суны чаштыр-чоштыр китереп, өйгә йөгердем. 41) Батырлык эшләргә тырышуым тагын кичекте инде...

*(Р. Гыйззәтуллин буенча)*

**28.** 18 нче җөмләдә <…> тамгасы урынына куелырга тиеш тыныш билгесен билгеләгез.

1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) тыныш билгесе куелмый

**29.** 19 нчы җөмләдә өтернең ни өчен куелганын билгеләгез.

1) Кереш һәм эндәш сүзләр җөмләдә өтер белән аерылалар.
2) Тиңдәш кисәкләр арасына өтер куела.
3) Кушма җөмләдәге гади җөмләләр өтер белән аерылалар.
4) Җөмләнең аерымланган кисәкләре өтер белән аерылалар.

**30.** 21 нче җөмләнең төрен билгеләгез:

1) гади, җәенке, ике составлы җөмлә
2) иярченле кушма җөмлә
3) тезмә кушма җөмлә
4) катнаш кушма җөмлә

## 2 нче өлеш

***Әлеге өлештәге биремнәрне үтәгәндә, үз җавапларыгызны 1 нче номерлы җавап бланкында 31-38 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда, буш шакмаклар калдырырга ярамый. Тел терминнарын тулы, дөрес һәм баш килештә язу таләп ителә.***

***31 – 33 нче биремнәргә җавапларны сүзләр белән языгыз.***

**31.** 3 нче җөмләдә аерып бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый?

**32.** 12-15 нче җөмләләрдән бәйлекне табып языгыз.

**33.** 16 нчы җөмләдә күп нокталар урынына кайсы тыныш билгесе куела?

***34 - 38 нче биремнәргә җавапларны цифр белән күрсәтегез.***

**34.** 17-20 нче җөмләләрдән ирен гармониясенә буйсынган сүз булган җөмлә санын языгыз.

**35.** 13-16 нчы җөмләләр арасыннан тезмә кушма җөмләнең санын языгыз.

**36.** 15-18 нче җөмләләр арасыннан *выносливый* сүзенең татарчага тәрҗемәсе булган җөмләнең санын языгыз.

**37.** 10-13 нче җөмләләр арасыннан бер составлы фигыль җөмләнең санын күрсәтегез.

**38.** 20-40 нчы җөмләләр арасыннан сыйфат фигыль кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

***Барлык җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.***

## 3 нче өлеш

***Әлеге өлешкә җавапны 2 нче номерлы бланкта эшләгез. Башта биремнең номерын күрсәтегез (39), аннан соң инша языгыз.***

**39.** Текст нигезендә сочинение языгыз.

Текст авторы тәкъдим иткән проблемаларның берсен формалаштырыгыз һәм аңлатыгыз (цитаталар китерү белән артык мавыкмагыз).

Автор (хикәяләүче) позициясен формалаштырыгыз. Укылган текст авторының фикерләре белән килешү яки килешмәвегезне языгыз, сәбәбен аңлатыгыз. Үз җавабыгызны, беренче чиратта, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләрегезгә нигезләнеп дәлилләгез (беренче ике дәлил игътибарга алыначак).

Иншаның күләме 150 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми. Әгәр инша сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Иншаны пөхтә, аңлашылырлык итеп языгыз.

# Татар теленннән имтихан эшен бәяләү системасы

## 1 нче өлеш

1 нче өлешнең һәм бирәмендәге дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.

Ике һәм күбрәк (шул исәптән дөрес җавап та), хата җавап яки җавап булмаса, 0 балл куела.

| Бирем номеры | Җавап | Бирем номеры | Җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 16 | 2 |
| 2 | 2 | 17 | 1 |
| 3 | 1 | 18 | 4 |
| 4 | 4 | 19 | 1 |
| 5 | 2 | 20 | 1 |
| 6 | 3 | 21 | 2 |
| 7 | 4 | 22 | 4 |
| 8 | 2 | 23 | 1 |
| 9 | 3 | 24 | 1 |
| 10 | 2 | 25 | 3 |
| 11 | 4 | 26 | 4 |
| 12 | 1 | 27 | 3 |
| 13 | 2 | 28 | 1 |
| 14 | 3 | 29 | 4 |
| 15 | 1 | 30 | 2 |

## 2 нче өлеш

| Бирем номеры | Җавап |
|---|---|
| 31 | исем |
| 32 | белән |
| 33 | өтер |
| 34 | 19 |
| 35 | 14 |
| 36 | 16 |
| 37 | 13 |
| 38 | 20, 24, 31, 40 |

## 3 НЧЕ ӨЛЕШНЕҢ СЫЙФАТЛАМАСЫ

1) Барысы да шул китаплар укудан башланды инде. 2) Чөнки бөтенесендә батырлар турында язылган. 3) Берсе – суда батучыны, икенчесе баланы ***янгыннан*** коткарган. 4) Әле тагын күпме шундый китаплар бардыр.

5) Батырлык!

6) Их, берәр батырлык эшләсәң икән ул. 7) Эшләр идең дә, кешеләр сиңа:

– Исәнме, Хәлим батыр! – диярләр иде. 8) Нинди рәхәт булыр иде. 9) Тик әле болар хыял гына. 10) Ләкин мин дә берәр батырлык эшләячәкмен. 11) Ул вакытта:

– Укымыйсың, тәртип бозасың, – дип бәйләнеп йөрүче сыйныфташым Зәнфирәнең дә авызы капланыр. 12) Ә мин аңа эндәшмәм дә. 13) Менә күрерсез!

14) Шундый уйлар белән кыш үтте, яз җитте. 15) Ләкин батырлык эшләп булмый гына бит. 16) Батырлар түземле <…> чыдам булалар икән. 17) Укыган китапларымдагы шул сүзләр искә төшә дә күңелгә рәхәт булып китә. 18) Димәк <…> көтәргә!

19) Бүген мәктәптән кайткач, кулыма озын таяк алдым да елга буена төшеп киттем. 20) Язгы ташу азрак тынды тынуын, шулай да күңелдә бер уй кайный әле: суга дип төшкән берәр апа бата башламасмы икән? 21) Әгәр бата башласа, мин аңа ярдәмгә ташланачакмын, үзен судан тартып чыгарырмын. 22) Шулай итеп, батыр булачакмын.

23) Тик елга буйлап ике-өч мәртәбә урап килсәм дә, андый нәрсә күзгә чалынмады. 24) Өметемне өзеп, кайтырга торганда, су буена төшеп килүче бала-чага тавышы ишетелде. 25) Мин тизрәк шунда йөгердем. 26) Анда Зәнфирәнең сеңлесе Фәния, тагын бер-ике кызчык иде. 27) Булды бу болай булгач, дип уйлап алдым мин.

28) – Әй, сез, – дим, – боз өстендә йөзәсегез киләме?

29) – Килә, Хәлим абый, бик тә килә! –диләр. 30) Шатланышып, яныма йөгереп килделәр.

31) – Утырыгыз менә шушысына! – дидем мин, яр кырыенда яткан бозга күрсәтеп. 32) Үзем алдагы басмага карап-карап алам. 33) Янәсе, кызларны агызып җибәрәм дә, йөгереп барып, басмадан берәм-берәм эләктереп алам үзләрен. 34) Кызлар боз өстенә менеп басуга, яр башыннан торып, таяк белән аны кузгатырга тотындым. 35) Боз кисәге кузгалмый да, кузгалмый гына бит. 36) Менә бер заманны... 37) Бер заманны, таягым сынып китеп, үзем яр астына мәтәлдем. 38) Кызларга нәрсә, көлешә-көлешә, ярдәмгә ашыктылар. 39) Тырыша торгач, судан да тартып чыгардылар. 40) Мин, итек эченә тулган бозлы суны чаштыр-чоштыр китереп, өйгә йөгердем. 41) Батырлык эшләргә тырышуым тагын кичекте инде...

*(Р. Гыйззәтуллин буенча)*

| **Текст турында мәгълүмат** |
|---|
| Текст Рафис Әхәт улы Гыйззәтуллин хикәясеннән кыскартып алынды. |

| | |
|---|---|
| **Төп проблема(лар)** | Батырлык.<br>Әлеге төшенчәне һәркем үзенчә аңлый.<br>Һәркемнең батыр буласы, илне шаулатырлык эшләр эшлисе килә. |
| **Автор позициясе** | Батырлык турында һәрберебез хыялланса да, кеше тормышындагы батырлык дигән иң гүзәл мизгелнең нәрсә икәнен без әле белеп бетермибез. Тирә-юньдәгеләр күзенә геройлар булып күренү өчен генә, төрле ысуллар уйлап табып, үз-үзләренә хөрмәт уятырга омтылу бер дә дөрес түгел. Андый кешеләрне батыр дип булмый. |

## Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен (82 код) имтихан эшен бәяләү критерийлары

| № | *Бәяләү критерийлары* | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| **К1** | **Чыганак тексттагы проблемаларны формалаштыру** | |
| | Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен (теге яки бу формада) дөрес формалаштырган.<br>Проблеманы аңлау яки формалаштыруга бәйле фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен дә дөрес формалаштыра алмаган. | 0 |
| **К2** | **Чыганак текстның формалаштырылган проблемасын аңлату** | |
| | Имтихан бирүче формалаштырган проблема чыганак текстка нигезләнеп аңлатылган. Язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле фактик хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче формалаштырган чыганак текст проблемасы аңлатылган,<br>**ләкин**<br>чыганак текстка нигезләнмәгән<br>**яки**<br>язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1 фактик хата бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче формалаштырган проблема аңлатылмаган,<br>**яки**<br>язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1дән артык фактик хатасы бар,<br>**яки**<br>имтихан бирүче формалаштырмаган башка проблема аңлатылган, | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | **яки**<br>аңлатмалар урынына язмада текстның яки аның өзегенең эчтәлеге генә бирелгән,<br>**яки**<br>аңлатмалар урынына чыганак тексттан күләмле өзек кенә китерелгән. | |
| **К3** | **Чыганак текст авторының позициясен чагылдыру** | |
| | Имтихан бирүче чыганак текст авторының (хикәяләүченең) аңлатылган проблемага бәйле позициясен дөрес формалаштырган.<br>Чыганак текст авторының позициясен аңлауга бәйле фактик хаталар юк.<br>Автор позициясен аңлауда фактик хаталар юк. | 1 |
| | Чыганак текст авторының позициясе имтихан бирүче тарафыннан дөрес формалаштырылмаган,<br>**яки**<br>чыганак текст авторының позициясе формалаштырылмаган. | 0 |
| **К4** | **Имтихан бирүченең проблемага карата үз фикерен дәлилләве** | |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (2 дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе матур әдәбиятка, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый). | 3 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2 дән ким булмаган дәлил китергән),<br>**яки**<br>матур әдәбиятка, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (1 дәлил китергән). | 1 |
| | Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, ләкин дәлилләмәгән,<br>**яки**<br>имтихан бирүче фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән,<br>**яки**<br>имтихан бирүче фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| **К5** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **К6** | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада имтихан бирүченең фикере төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| **К7** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **К8** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **К9** | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| **К10** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| **К11** | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| **К12** | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк | 1 |
| | Фактик хаталары бар | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **23** |

Грамоталылыкны (К7-К10) бәяләгәндә, укучы язмасының күләме исәпкә алына. Таблицада күрсәтелгән бәяләү нормалары күләме 130-250 сүздән торган язмаларны бәяләү өчен тәкъдим ителә.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән кимрәк булса, андый эш 0 балл белән бәяләнә, бирем үтәлмәгән булып санала.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 130 сүзгә кадәр күләмдә булса, К7-К10 нчы критерийлардагы хаталары киметелә. **Бу критерийлар буенча 2 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар);

К8 – тыныш билгеләренә кагылышлы хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар).

**Бу критерийлар буенча 1 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – хатасы 2 дән артык түгел;

К8 – 1-3 хатасы бар;

К9 – грамматик хаталары юк;

К10 – сөйләмгә кагылышлы хаталары 1 дән артык түгел.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 130 сүзгә кадәр күләмдә генә булса, К7-К12 критерийлары буенча югары балл бөтенләй куелмый.

Әгәр укучының язмасында автор текстының эчтәлеге генә чагылыш тапса яки автор тексты бернинди аңлатмаларсыз күчереп кенә алынган булса, К1-К12 нче критерийлары буенча бу эш 0 балл белән бәяләнә. Чыганак текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми.